КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 25 март г.Казань № 183

2024 елга ачык өстенлекләр реестрын
раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Республика башкарма хакимият органнары тарафыннан Татарстан Республикасының норматив хокук актларын эшләгәндә һәм гамәлгә ашырганда җәмәгатьчелек фикерен исәпкә алуны оештыру тәртибе турында» 2007 ел, 19 март, 90 нчы карарын тормышка ашыру максатларында, 2023 елда үткәрелгән социологик тикшеренүләр нәтиҗәләренә таянып, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән 2024 елга ачык өстенлекләр реестрын (алга таба – Реестр) расларга.

2. Республика башкарма хакимият органнарына:

Реестрда күрсәтелгән ачык өстенлекләрне тормышка ашыру чараларын Татарстан Республикасының гамәлдәге һәм эшләнә торган дәүләт программаларына кертүне тәэмин итәргә, шулай ук боерык белән аларны тормышка ашыру мониторингын контрольдә тоту буенча җаваплы затларны билгеләргә;

2024 елның 1 декабреннән дә соңга калмыйча, ачык өстенлектәге төп проблемалар исемлеге яктылыгында Реестрда күрсәтелгән ачык өстенлекләрне тормышка ашыру буенча башкарылган эш турындагы мәгълүматны «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Татарстан Республикасының Икътисадый һәм социаль тикшеренүләр үзәге» дәүләт бюджет учреждениесенә кертергә.

3. Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгына, башкарма хакимиятнең кызыксынучы республика органнары белән берлектә, массакүләм мәгълүмат чараларында республика башкарма хакимият органнарының Реестрда күрсәтелгән ачык өстенлекләрне тормышка ашыру буенча эш барышын һәм нәтиҗәләрен даими яктыртуны тәэмин итәргә.

4. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2023 елга ачык өстенлекләр реестрын раслау турында» 2023 ел, 17 апрель, 482 нче карары үз көчен югалткан дип танырга.

5. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Премьер-министрының беренче урынбасары Р.К.Нигъмәтуллинга йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2024 ел, 25 март, 183 нче
карары белән расланды

2024 елга ачык өстенлекләр реестры

| Т/с | Өстенлекнең исеме | Өстенлекне билгеләгән халык өлеше, процент | Социологик тикшеренүләр нәтиҗәләре буенча формалаштырылган төп проблемалар исемлеге |
|---|---|---|---|
| 1. | Бәяләр һәм тарифлар артуны тоткарлау | 54,0 | азык-төлек продуктларына, торак күчемсез мөлкәткә һәм торак-коммуналь хезмәтләр тарифларына бәяләр арту;<br>азык-төлек продуктларын сатып алу һәм торак-коммуналь хезмәтләргә түләү чыгымнары гаиләнең чыгымнар күләмендә иң зур өлешне алып тора |
| 2. | Алкоголизмга һәм наркомониягә каршы көрәш | 37,8 | наркотик чаралардан файдалану мөмкинлеге булу |
| 3. | Ришвәтчелеккә һәм коррупциягә каршы тору | 34,9 | гражданнарның хокукый культурасы түбән булу;<br>хокук саклау органнарына ышану дәрәҗәсе югары булмау |
| 4. | Әйләнә-тирә мохитне саклау һәм яхшырту | 32,7 | гражданнарның экологик культурасы түбән булу;<br>атмосфера һавасы, эчәргә яраклы су канәгатьләнерлек дәрәҗәдә булмау, елга, буа, күлләр пычрану;<br>юлларда автомобильләр күп санда булу;<br>урамнарда чүп савытлары һәм ишегалларында контейнерлар җитәрлек санда булмау;<br>рөхсәт ителмәгән чүплекләр барлыкка килү;<br>ишегалларында һәм урамнарда чүп-чарны җыештыру сыйфатлы булмау |